**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында гражданнар җыены**

КАРАР

25.11.2025 ел № 6

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында
гражданнарга үзара салымын кертү һәм куллану турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Уставының 22 ст., Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләре буенча гражданнар җыены уздыру турында” 2025 елның 15 ноябрендәге 5 нче номерлы карары нигезендә 2025 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыенында 2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, 18 яшькә кадәрге балалары булган аз керемле күпбалалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

«1. Һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү: (Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәлен ремонтлау һәм реконструкцияләү)

2. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү: (үлән чабу , ягулык-майлау материаллары һәм шартнамә буенча хезмәт өчен түләү; трактор тоту, запас частьлар сатып алу, хезмәт хакы түләү; балалар

мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу, материал сатып алу һәм урнаштыру)

3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту , җирлек юллары эчендә ремонтлау (Урман урамындагы чокырларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту)

4. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау: (канализация насос станцияләрен койма белән әйләндереп алу, материал сатып алу һәм урнаштыру)

Узган еллардан калган үзара салым акчаларын кар чистартуга тотарга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Ижевка авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлеге башлыгы ____________ Р.Т.Мәсәгутова
(имза) (имзаны киңәйтү)